ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РУССКО-ОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Профсоюзная, дом 7а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘШНӘГЕАВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422642, Рус Әшнәге,
Профсоюз урамы, 7а нче йорт,

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, e-mail:Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2017 елның 12 июле. Рус Әшнәге ав. № 3

Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ
җәза бирелә торган оешмалар исемлеген
һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тәкъдимен карап, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру максатларында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Рус Әшнәге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Суд карарының законлы көченә кергән карары буенча административ җәза үтәү рәвешендә башкарылучы мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри булып саналуын исәпкә алып, №1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә административ җәза үтәтү өчен мәҗбүри эш төрләрен билгеләү мәҗбүри эш дип санала.

2. Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларның китү урыннарын булып - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре санала.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген № 2 кушымта нигезендә расларга.

4. Мәҗбүри эшләрне күрсәтелгән административ җәза билгеләнгән затларның яшәү урыны буенча башкарырга кирәк.

5. Административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләр башкара торган оешма җитәкчеләренә Административ хокук бозулар турында Россия

Федерациясе кодексында һәм хезмәт законнарында каралган вазыйфалар йөкләнә дип билгеләргә.

6. Суд приставларының федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Балык Бистәсе район бүлегенә административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләр башкара торган оешмалар администрацияләренә хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Башкарма комитетының «мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәүче оешмалар исемлеген һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында»2014 ел, 20 гыйнвар, 2 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

8. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

9. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәгеавыл җирлеге башлыгы В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл
җирлеге башкарма комитеты 2017
елның 12 июле, № 3
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге территориясендә административ җәза үтәтү өчен мәҗбүри эш төрләре**

1. Тышкы төзекләндерү объектларын яшелләндерү, агымдагы карап тоту һәм үстерү буенча эшләр.

2. Урамнарны җыештыру.

3. Лесосекларга бүлеп бирү (визалар кисү, делянка баганалары ясау һәм урнаштыру).

4. Урман фонды территорияләрен төзекләндерү (урман кишәрлекләрен рөхсәтсез җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын, беседкаларны урнаштыру).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл
җирлеге башкарма комитеты 2017
елның 12 июле, № 3
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге башкарма комитеты.

2. «Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).

3. «Кама урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).